ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail:Kach.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**19.03.2016 ел** **№ 4**

## «2016 - 2018 елларга Кәче авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программаны раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2016-2018 елларга Кәче авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын расларга.
2. Чараларны үтәүчеләргә «2016-2018 елларга Кәче авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:\pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Т.Д. Закиров

Арча муниципаль районы
Кәче авыл җирлеге Башкарма
комитетының
19.03.2016 ел, № 4 карары белән
РАСЛАНДЫ

**«2016 - 2018 елларга Кәче авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программа**

Гомуми нигезләмәләр

Программаның төп максаты - Кәче авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү һәм шул нигездә халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, халыкны эш белән тәэмин итү, җитештерү, хезмәт һәм интеллектуаль потенциалны үстерү.

Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| 1. Муниципаль программа исеме | «2016 - 2018 елларга Кәче авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программасы |
| 2. Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнар; 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы<br>«Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында»<br>Татарстан Республикасында |
| 3. Муниципаль программаның муниципаль заказчысы | Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. Муниципаль программаның төп максаты | - кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен уңайлы мохит булдыру;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлыкның гамәлдәге субъектларын саклап калуга һәм булдыруга ярдәм итү;<br><br>- базарны җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре белән баету; |

| | |
|---|---|
| | - авыл җирлегендә яшәүче халыкны эш белән тәэмин итү. |
| 5. Муниципаль программаның төп бурычлары | Барлык дәрәҗәләрдә бизнес һәм хакимиятнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының (алга таба - Субъектлар) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның (алга таба - Оешманың) үзара хезмәттәшлеге рәвешләрен һәм механизмнарын үстерү һәм камилләштерү;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше мониторингы;<br><br>-кече һәм урта эшкуарлык турында уңай җәмәгать фикерен булдыру;<br><br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) алга җибәрүдә ярдәм күрсәтү. |
| 6. Муниципаль программаның төп чараларын үтәүчеләр | Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты. |
| 7. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2016-2018 еллар |
| 8. Муниципаль программа максатларына ирешү индикаторлары | - кече эшкуарлык субъектлары санын арттыру;<br><br>- өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру;<br><br>- җитештерү күләмнәрен үстерү, продукция сату базарын киңәйтү;<br><br>- җирлек территориясендә җитештерелгән товарлар төрләрен киңәйтү. |
| 9. Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | - җирлек бюджеты акчалары - 30 мең сум, |

## 1 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАРЫН ТАСВИРЛАУ

Кече эшкуарлык - икътисадый һәм сәяси тотрыклылык, иҗтимагый үсеш, товарларның яңа төрләрен үзләштерү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү өчен принципиаль әһәмияткә ия икътисадның өстенлекле секторы. Кәче авыл җирлегендә 2016 елның 1 гыйнварына кече һәм урта эшкуарлыкның 2 субъекты эшчәнлек алып бара.

## 2 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ РЕАЛИЗАЦИЯСЕ

Программаны гамәлгә ашыру срогы2016 елдан 2018 елга кадәр

## 3 нче бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТАСВИРЛАУ

| № т/б | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Чараларны башкаручылар | Район бюджеты акчалары исәбеннән финанслау күләме (еллар буенча) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1 елы | 2 елы | 3 елы | Барлыгы |
| Муниципаль программаның максаты | | | | | | | |
| 1.1.Төп чара | | - товарларны, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне сату базарын киңәйтү максатларында күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнашуга җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын җәлеп итү; | Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.2.Төп чара | | Дәүләт ярдәмен алу мәсьәләләре буенча җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен консультацияләр оештыру | Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.4 | | Уңайлы иҗтимагый климат тудыру максатында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурслар үткәрү һәм массакүләм | Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты | 10 т.б. | 10 т.б. | 10 т.б. | 10 т.б. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәгълүмат чараларында уздырыла торган чараларны яктырту. | | | | | |

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫНЫҢ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | База нигезендә 2015 елның фактта | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның беренче елы | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның беренче елы | 3 ел Муниципаль программа |
|---|---|---|---|---|---|
| - кече эшкуарлык субъектлары санын арттыру; | Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны | 2 | 2 | 2 | 2 |
| - өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру;<br>- җирлек территориясендә җитештерелгән товарлар төрләрен киңәйтү. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан бирелгән эш урыннары саны<br>Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары җитештергән товарларның төрләре саны | 4<br>4 | 4<br>4 | 4<br>5 | 4<br>5 |

## 6 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

| . Финанслау чыгнаклары | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 елы программаны гамәлгә ашыруның | 2 елы . программаны гамәлгә ашыруның | 3 ел программаны гамәлгә ашыруның | муниципаль программаны гамәлгә ашыруның программаны гамәлгә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ашыруның |
| Җирле бюджет | 10 мең сум. | 10 мең сум. | 10 мең сум. | 30 мең сум. |

Программаның чараларын финанслау авыл җирлеге бюджеты исәбеннән башкарыла.

Программаны 2016 елда финанслауның гомуми күләме - 2018 елларда 30 мең сум тәшкил итә.

Бюджет акчалары күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле бюджетлар проектларын төзегәндә һәм караганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Т.Д.Закиров